ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

21 июня 2023 г.

**КАРАР**

№ 5350

Башкарма комитетның «Конкурентлы сатып алуларны үстерү агентлыгы» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2022 елның 4 апрелендәге 1792 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешнең 4 пунктчасы, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24, 5.25 пунктлары, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Конкурентлы сатып алуларны үстерү агентлыгы» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2022 елның 4 апрелендәге 1792 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлектәге 1.1 пункт өстәргә:

«1.1. «Конкурентлы сатып алуларны үстерү агентлыгы» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифлар муниципаль йөкләмә белән билгеләнгән хезмәтләргә кагылмый.»;

2) кушымтада:

- 9 пунктта «дәүләт яки муниципаль» сүзләрен төшереп калдырырга;

- 10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Электрон сәүдә мәйданчыкларында тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) өчен бәя тәкъдиме бирү (1 сатып алу) – 812,00 сум»;

- 11 пунктта «дәүләт яки муниципаль» сүзләрен төшереп калдырырга;
- 12, 13 пунктлар үз көчен югалткан дип танырга;
- түбәндәге эчтәлектәге 17 пункт өстәргә:

«17. Котировкаларның электрон запросын үткәрү юлы белән тәэмин итүчене (подрядчыны, башкаручыны) билгеләү – 3000,00 сум».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов